ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 12 августындагы 40 номерлы килешүне раслау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 12 августындагы 40 номерлы килешүне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1572-VI ДС

# РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӘМ МАРИЙ ЭЛ РЕСПУБЛИКАСЫ АРАСЫНДАГЫ ЧИК УРНАШКАН УРЫННЫ БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА КИЛЕШҮ

2022 елның «12» августы

Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Миңнеханов Рөстәм Нургали улы, бер яктан, һәм Марий Эл Республикасы исеменнән Марий Эл Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Марий Эл Республикасы Башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Зайцев Юрий Викторович, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясенә, «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Марий Эл Республикасы Конституциясе, «Марий Эл Республикасының административ-территориаль төзелеше (бүленеше) мәсьәләләрен хәл итү тәртибе турында» 2006 елның 3 маендагы 22-З номерлы Марий Эл Республикасы Законына нигезләнеп, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеде.

1 статья

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны әлеге Килешүгә 1 нче кушымтада каралган Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чикнең график тасвирламасы һәм әлеге Килешүгә 2 нче кушымтада каралган Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чикнең текстлы тасвирламасы нигезендә билгеләнде дип санарга.

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чикнең координаталы тасвирламасы, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган чикнең график һәм текстлы тасвирламасына нигезләнеп, Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла. Күрсәтелгән чикнең координаталы тасвирламасын килештерү Якларның вәкаләтле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2 статья

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чик әлеге Килешү төзелү нәтиҗәсендә үзгәрми, күрсәтелгән чикнең урнашкан урыны һәм узуы тасвирламасы мәсьәләләре буенча фикер каршылыклары юк.

3 статья

Әлеге Килешү Якларның дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары тарафыннан аның раслануы турында хокукый актлар үз көченә кергән көннән үз көченә керә.

4 статья

Әлеге Килешүгә Яклар тарафыннан өстәмә килешүләр төзелү юлы белән үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

5 статья

Әлеге Килешү бер үк төрле юридик көчкә ия дүрт нөсхәдә төзелде. Һәр Якка әлеге Килешүнең бер нөсхәсе бирелә, өченче һәм дүртенче нөсхәләр тиешенчә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Марий Эл Республикасы Дәүләт Собраниесенә тапшырыла.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы өчен | Марий Эл Республикасы өчен |
| Татарстан Республикасы Президенты | Марий Эл Республикасы Башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы |
| _______________ Р.Н. Миңнеханов<br>М.У. | _______________ Ю.В. Зайцев<br>М.У. |

Россия Федерациясе субъектлары –
Татарстан Республикасы һәм
Марий Эл Республикасы арасындагы
чик урнашкан урынны билгеләү турында
2022 елның 12 августындагы килешүгә
1 нче кушымта

# РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӘМ МАРИЙ ЭЛ РЕСПУБЛИКАСЫ АРАСЫНДАГЫ ЧИКНЕҢ ГРАФИК ТАСВИРЛАМАСЫ

Россия Федерациясе субъектлары –
Татарстан Республикасы һәм
Марий Эл Республикасы арасындагы
чик урнашкан урынны билгеләү турында
2022 елның 12 августындагы килешүгә
2 нче кушымта

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӘМ МАРИЙ ЭЛ РЕСПУБЛИКАСЫ АРАСЫНДАГЫ ЧИКНЕҢ ТЕКСТЛЫ ТАСВИРЛАМАСЫ**

Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чикнең әлеге текстлы тасвирламасында Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чикнең график тасвирламасында күрсәтелгән чикнең борылыш нокталарының (чикнең текстлы тасвирламасының үзгәрү нокталарының) шартлы билгеләре (номерлары) кулланылды.

Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасында чик Татарстан Республикасы, Марий Эл Республикасы һәм Чуваш Республикасы арасындагы чикләрнең тоташу (уртак) ноктасы булып торучы, Идел елгасы (Куйбышев сусаклагычы) акваториясендә Чуваш Республикасы Козловский районы Курочкино авылыннан төньяк-көнчыгышка 1,22 км ераклыкта урнашкан 1 нче ноктадан уза.

1 нче ноктадан 2 нче ноктага кадәр чик Идел елгасы (Куйбышев сусаклагычы) акваториясе буйлап көнчыгыш юнәлештә 4,35 км Краснозаринск файдалы казылмалар ятмалары һәм Улитино-Курочкино файдалы казылмалар ятмалары арасыннан, алга таба 3,89 км көнбатыш и төньяк-көнбатыш юнәлештә Идел елгасы (Куйбышев сусаклагычы) култыгы буйлап култыкның көнбатыш ярына кадәр, алга таба 0,09 км автомобиль юлына кадәр уза, аны кисеп үтә, аннары 0,05 км төньяк юнәлештә автомобиль юлының көнбатыш ягыннан уза, алга таба көнбатыш юнәлештә 0,07 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 145 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза.

2 нче ноктадан 3 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 0,11 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 145 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Зеленодольск шәһәре һәм Волжск шәһәре арасындагы автомобиль юлына кадәр уза, аны кисеп үтә, алга таба 0,42 км Марий Эл Республикасы Волжск шәһәренең Парники урамындагы машиналар юлының көнчыгыш ягы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатыш юнәлештә 0,16 км тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, алга таба, тимер юлны кисеп үтеп, төньяк юнәлештә 0,73 км һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 137 нче, 128 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, аннары көнбатыш юнәлештә 0,49 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 118 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, алга таба төньяк юнәлештә 0,5 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 118 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза.

3 нче ноктадан 4 нче ноктага кадәр чик көнбатыш юнәлештә 0,73 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 105 нче, 104 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, аннары 0,19 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының урман кордоны участокларының көньяк чиге буйлап, алга таба төньяк юнәлештә 0,07 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының урман кордоны һәм Марий Эл Республикасы, Волжск шәһәре, Пограничная урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлегенең чиге буенча уза, аннары чик 0,08 км көнбатыш юнәлештә Марий Эл Республикасы, Волжск шәһәре,

Пограничная урамы, 7 нче йорт, 8 нче йорт, 9 нчы йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлекләренең төньяк ягы буйлап бара.

4 нче ноктадан 5 нче ноктага кадәр чик төньякка таба 0,03 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 104 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча, алга таба, сынык сызык ясап, төньяк юнәлештә 0,36 км Марий Эл Республикасы, Волжск шәһәре, Зеленая урамы, 26 нчы йорт, 28 нче йорт, 30 нчы йорт һәм 37 нче йорт, Пушкин урамы, 42 нче йорт, 44 нче йорт һәм 49 нчы йорт һәм Крайняя урамы, 225 нче йорт, 219 нчы йорт, 227 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлекләренең көнчыгыш ягы буйлап, аннары төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,38 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 104 нче, 87 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, алга таба 1,52 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 87, 73, 57 нче урман кварталлары һәм Волжск шәһәренең шәһәр корылмалары арасындагы чик буенча, алга таба 3,74 км, электр тапшыру линияләрен һәм Р-175 Казан – Зеленодольск – Волжск – Йошкар-Ола автомобиль юлын кисеп үтеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 48, 40, 32, 22 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Алексеевский урманчылыгының Алексеевский участок урманчылыгындагы 97, 91, 87, 85 нче урман кварталлары арасындагы чик буенча уза.

5 нче ноктадан 6 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,42 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 22 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, аннары 1,05 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 22 нче һәм 14 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Алексеевский урманчылыгының Алексеевский участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталы арасындагы чик буенча, алга таба 1,04 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 14 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары чик шул ук юнәлештә 0,58 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 14 нче һәм 7 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Волжск районы Александровка авылының көньяк-көнчыгыш чиге арасындагы чик буенча, алга таба 1,27 км электр тапшыру линияләре буйлап Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 7 нче һәм 8 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза.

6 нчы ноктадан 7 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 8 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап тимер юлга кадәр 0,47 км, алга таба 3,32 км шул ук юнәлештә Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 8, 9, 10, 3 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, аннары 0,85 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталы һәм Марий Эл Республикасының Волжск районы Краснознаменский хуторының көньяк-көнчыгыш чиге арасындагы чик буенча, алга таба 2,54 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталының төньяк һәм көнчыгыш чиге буйлап, аннары 0,52 км төньякка таба Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза.

7 нче ноктадан 8 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә 0,94 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Зеленодольск участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары чик шул ук юнәлештә 5,22 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Әйшә участок

урманчылыгындагы 4, 5, 6, 7 нче һәм 8 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза.

8 нче ноктадан 9 нчы ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 0,87 км урман полосасының көнбатыш ягы буенча уза.

9 нчы ноктадан 10 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,13 км, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Әйшә участок урманчылыгындагы 187 нче урман кварталы кишәрлекләренең төньяк чиге буйлап, аннары 0,48 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча уза, алга таба чик урман полосасының төньяк ягыннан 0,36 км уза.

10 нчы ноктадан 11 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 0,45 км урман полосасының көнбатыш ягыннан, аннары 0,64 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 1,15 км урман полосасының көнбатыш ягыннан уза.

11 нче ноктадан 12 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 1,88 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Әйшә участок урманчылыгындагы 3 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, алга таба 0,45 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Уразлы елгасына кадәр уза.

12 нче ноктадан 13 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 3,37 км Уразлы елгасы уртасыннан агым уңаена аска таба уза.

13 нче ноктадан 14 нче ноктага кадәр чик көнбатыш юнәлештә 0,47 км урман массивының көньяк чиге буйлап, алга таба төньяк-көнбатыш юнәлештә 1,43 км, сынык сызык ясап, урманның аерымланган участогы буйлап, аннары 1,06 км урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, алга таба 0,92 км Татарстан Республикасы Зеленодольск урманчылыгының Әйшә участок урманчылыгындагы 184 нче урман кварталы кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, аннары 0,20 км урман полосасының көньяк ягы буйлап уза.

14 нче ноктадан 15 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,46 км урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап, аннары 0,87 км, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 0,81 км урман полосасының төньяк ягы буйлап, аннары 0,16 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 1,90 км төньяк юнәлештә урман полосасының көнбатыш ягы буйлап, аннары 0,94 км төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

15 нче ноктадан 16 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,52 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 0,79 км урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап, алга таба 0,78 км, Петьялка елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

16 нчы ноктадан 17 нче ноктага кадәр чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,62 км көньяк-көнчыгыш юнәлештә, аннары 1,04 км көньяк-көнбатыш юнәлештә Петьялка елгасына кадәр уза, алга таба чик 2,39 км, Зеленый Ключ елгасын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгыш юнәлештә, аннары көньяк юнәлештә 0,76 км Петьялка елгасы уртасыннан агымга каршы өскә таба уза.

17 нче ноктадан 18 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,33 км чокыр буйлап, алга таба 0,62 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 0,35 км урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап, аннары 1,63 км, исемсез инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

18 нче ноктадан 19 нчы ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә 0,54 км урман полосасының төньяк ягы буйлап, алга таба 0,53 км урманның аерымланган участогы буйлап, аннары 0,71 км урман полосасының төньяк ягы буйлап, алга таба 0,80 км көнчыгыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 0,59 км көньяк юнәлештә урман массивының көнбатыш ягы буйлап һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 0,59 км көнчыгыш юнәлештә, Токторали елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

19 нчы ноктадан 20 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 0,58 км урман полосасының көнбатыш ягы буйлап, алга таба 0,26 км, исемсез инешне кисеп үтеп, урманның аерымланган участогының көнчыгыш ягы буйлап, аннары 1,29 км урман полосасының көнбатыш ягы буйлап, алга таба 0,38 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 57 нче урман кварталы кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап, аннары 0,25 км шул ук юнәлештә урман участогы буйлап, алга таба 0,22 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 57 нче урман кварталы кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап, аннары 0,41 км төньяк-көнбатышка таба урман участогы буйлап, алга таба 0,23 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 57 нче урман кварталы кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, аннары 0,83 км төньякка урман полосасының көнчыгыш ягы буйлап һәм алга таба 0,61 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

20 нче ноктадан 21 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә 0,54 км урман полосасының көньяк ягы буйлап, аннары 2,44 км төньякка таба, исемсез инешне кисеп үтеп, Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 55, 53 нче һәм 52 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза.

21 нче ноктадан 22 нче ноктага кадәр чик гомуми төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,82 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 52 нче урман кварталы һәм 87 нче урман кварталы кишәрлекләре төньяк чиге буйлап, алга таба 0,90 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 0,44 км, исемсез инешне һәм Джанок елгасын кисеп үтеп, Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 87 нче урман кварталы кишәрлегенең көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап, алга таба 0,25 км урманның аерымланган участогының көньяк чиге буйлап, аннары шул ук юнәлештә 3,90 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 41, 42, 43 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, алга таба 0,94 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

22 нче ноктадан 23 нче ноктага кадәр чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк юнәлештә 2,44 км, төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,40 км, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көнчыгыш юнәлештә 1,37 км уза.

23 нче ноктадан 24 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 4,27 км, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Ашыт елгасын кисеп үтеп, аерымланган урман массивының көнчыгыш ягы һәм Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 36 нчы кварталы кишәрлегенең көнбатыш ягы арасынннан уза.

24 нче ноктадан 25 нче ноктага кадәр чик, сынык сызык ясап, гомуми көнчыгыш юнәлештә 1,08 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 1,06 км Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 100 нче һәм 101 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, аннары 3,12 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 37 нче урман кварталы кишәрлеге һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 101, 102, 104 нче урман кварталлары арасындагы чик буйлап уза, алга таба чик 0,60 км төньяк-көнчыгышка таба Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 104 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары 0,97 км төньякка таба Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 38 нче урман кварталы кишәрлеге һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 104 нче урман кварталы арасындагы чик буйлап, алга таба 0,70 км төньяк-көнчыгышка таба Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының

Красностекловарский участок урманчылыгындагы 104 нче, 103 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, алга таба 1,07 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 38 нче урман кварталы кишәрлеге һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 103 нче, 91 нче урман кварталлары арасындагы чик буйлап уза.

25 нче ноктадан 26 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнбатыш юнәлештә 2,81 км Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 91 нче һәм 90 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары 0,38 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетьский участок урманчылыгындагы 100 нче урман кварталы кишәрлеге һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 90 нчы урман кварталы арасындагы чик буйлап, алга таба 1,31 км, урман массивын кисеп үтеп, Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 90 нчы һәм 88 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза.

26 нчы ноктадан 27 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнбатыш юнәлештә 2,45 км Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 88 нче, 87 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, аннары көнбатыш юнәлештә 1,85 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 23 нче, 22 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 86 нчы, 85 нче урман кварталлары арасындагы чик буйлап Илеть елгасына кадәр, алга таба шул ук юнәлештә 2,12 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 21 нче, 20 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 84 нче, 83 нче урман кварталлары арасындагы ачыклык буенча уза.

27 нче ноктадан 28 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 3,56 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 15, 9, 5 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 76, 70, 66, 61 нче урман кварталлары арасындагы ачыклык буенча уза.

28 нче ноктадан 29 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 5,40 км, Яранка елгасын кисеп үтеп, Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Ашыт участок урманчылыгындагы 5, 2, 3, 1 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 56, 51, 45, 33, 34 нче урман кварталлары арасындагы ачыклык буенча, аннары 3,13 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетьский участок урманчылыгындагы 63, 53, 42 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 36, 37, 38 нче урман кварталлары арасындагы чик буйлап уза.

29 нчы ноктадан 30 нчы ноктага кадәр чик гомуми төньяк юнәлештә 4,97 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетьский участок урманчылыгындагы 42, 34, 29, 24 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 38, 19, 10, 6 нчы урман кварталлары арасындагы чик буйлап уза.

30 нчы ноктадан 31 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,2 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетьский участок урманчылыгындагы 24 нче, 19 нчы урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Кужерский урманчылыгының Красностекловарский участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталы арасындагы чик буйлап, алга таба 1,09 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетьский участок урманчылыгындагы 19 нчы, 14 нче урман

кварталлары көнбатыш чиге буйлап уза, аннары чик көнчыгышка таба 1,16 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетский участок урманчылыгындагы 14 нче урман кварталы һәм Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Моркинский участок урманчылыгындагы 112 нче урман кварталы арасындагы чик буйлап, алга таба 1,38 км, сынык сызык ясап, Илеть елгасын һәм урман массивын кисеп үтеп, Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетский участок урманчылыгындагы 15 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, аннары 1,35 км көньякка таба Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Моркинский участок урманчылыгындагы 113 нче урман кварталы һәм Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетский участок урманчылыгындагы 15 нче, 20 нче урман кварталлары арасындагы чик буйлап, алга таба 4,13 км гомуми юнәлештә төньяк-көнчыгышка таба Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Моркинский участок урманчылыгындагы 113 нче, 111 нче урман кварталлары һәм Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетский участок урманчылыгындагы 21, 16, 12, 11, 10 нчы урман кварталлары арасындагы чик буйлап, алга таба 1,37 км төньякка таба Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетский участок урманчылыгындагы 11 нче, 10 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза.

31 нче ноктадан 32 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә 0,83 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетский участок урманчылыгындагы 10 нчы урман кварталы һәм Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Моркинский участок урманчылыгындагы 108 нче урман кварталы арасындагы чик буйлап, алга таба көньяк юнәлештә 1,37 км Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетский участок урманчылыгындагы 10 нчы, 11 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары чик көнчыгышка таба 2,40 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба көньякка таба 0,18 км урман массивының көнбатыш ягы буйлап, аннары 0,72 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза. Алга таба чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,48 км урман полосасының төньяк-көнбатыш ягы буйлап, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатыш юнәлештә 1,36 км, алга таба, электр тапшыру линияләрен кисеп үтеп, төньяк юнәлештә 2,36 км уза.

32 нче ноктадан 33 нче ноктага кадәр чик гомуми көнчыгыш юнәлештә 3,71 км, Тюшумка елгасын кисеп үтеп, Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Моркинский участок урманчылыгындагы 101, 102, 103 нче урман кварталлары һәм Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетский участок урманчылыгындагы 2, 3, 4 нче урман кварталлары арасындагы чик буйлап уза.

33 нче ноктадан 34 нче ноктага кадәр чик көньяк юнәлештә 1,80 км, исемсез инешне һәм Тюшумка елгасын кисеп үтеп, Татарстан Республикасы Ислейтар урманчылыгының Илетский участок урманчылыгындагы 5 нче, 9 нчы урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, аннары 1,05 км урман полосасының көнчыгыш ягы буйлап, алга таба 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Уртемка елгасына кадәр уза.

34 нче ноктадан 35 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә 6,8 км Уртемка елгасы уртасыннан агым уңаена аска таба уза.

35 нче ноктадан 36 нчы ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 1,75 км Варангужская Речка елгасы уртасыннан агымга каршы өскә таба, алга таба шул ук юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,71 км исемсез инешкә кадәр, аннары 0,79 км агым уңаена өскә таба инеш буйлап, алга таба 1,53 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап исемсез инешкә кадәр уза. Аннары чик юнәлешен көнчыгышка таба үзгәртә һәм 1,80 км исемсез инеш уртасыннан Варангужская Речка елгасына койган урынга кадәр, алга таба 0,17 км көньякка таба Варангужская Речка елгасы уртасыннан агым уңаена аска таба уза, аннары чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,59 км көньяк-көнчыгышка таба, алга таба 0,37 км көньяк-көнбатышка таба уза.

36 нчы ноктадан 37 нче ноктага кадәр чик авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,99 км көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының читенә кадәр, аннары 2,14 км төньяк-көнчыгышка таба уза.

37 нче ноктадан 38 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 1,55 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба шул ук юнәлештә 1,33 км урман полосасының көнбатыш ягы билап, аннары 0,82 км урман полосасының көнчыгыш ягы буйлап, алга таба 1,04 км төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

38 нче ноктадан 39 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнбатыш юнәлештә 0,52 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба төньякка таба 0,72 км урман полосасының көнбатыш ягы буйлап Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Ключи-Сап торак пунктын һәм Марий Эл Республикасы Моркинский районы Шиньша торак пунктын тоташтыручы автомобиль юлы кисеп үтә. Аннары чик төньяк юнәлештә 1,27 км пар урман полосасы арасыннан, 0,17 км алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

39 нчы ноктадан 40 нчы ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 2,29 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

40 нчы ноктадан 41 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә 1,16 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Сап елгасына кадәр, алга таба 0,38 км көнчыгышка таба канау уртасыннан, аннары көнчыгышка, ә аннан соң төньякка таба 0,21 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба төньякка таба 2,12 км канауның көнчыгыш чите буйлап, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,17 км төньякка таба, аннан соң 0,06 км көнбатышка таба, аннары 0,31 км көньяк-көнбатышка таба канауга кадәр уза. Алга таба чик көньяк-көнбатыш юнәлештә 0,29 км канауның төньяк-көнбатыш ягы буйлап, аннары Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 119 нчы урман кварталы һәм Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Уньжинский участок урманчылыгындагы 101 нче, 95 нче урман кварталлары кишәрлекләре арасындагы чик буйлап 0,85 км көнбатышка таба, алга таба 1,20 км төньякка таба, аннары 0,65 км төньяк-көнчыгышка таба, алга таба 0,75 км көнчыгышка таба уза. Алга таба чик 0,64 км көньякка таба урман массивының көнчыгыш ягы буйлап, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 0,14 км көньяк-көнбатышка таба, алга таба, Шора елгасын кисеп үтеп, 0,20 км көньякка таба, аннары 0,29 км төньяк-көнчыгышка таба, алга таба 1,20 км төньяк-көнчыгышка таба канауның көньяк чите буйлап, аннары 0,94 км шул ук юнәлештә, Шора елгасын ике тапкыр кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

41 нче ноктадан 42 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,10 км канауның көньяк-көнбатыш чите буйлап, аннары көньяк-көнбатыш юнәлештә 0,92 км канау буенча, алга таба 1,03 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 119 нчы урман кварталы кишәрлекләре һәм Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Уньжинский участок урманчылыгындагы 102 нче урман кварталы арасындагы чик буйлап, алга таба көньякка таба 0,56 км Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Уньжинский участок урманчылыгындагы 102 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, аннары гомуми юнәлештә көньякка таба 2,60 км, Сапуньжинская Речка елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза. Алга таба чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә 2,06 км, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Ключи-Сап торак пунктын һәм Марий Эл Республикасы Моркинский районы Шоруньжа торак пунктын тоташтыручы автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 0,67 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап уза.

42 нче ноктадан 43 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,68 км, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 0,35 км көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягы буйлап, аннары, сынык сызык ясап, 4,36 км гомуми юнәлештә көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

43 нче ноктадан 44 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 3,71 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

44 нче ноктадан 45 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә 0,30 км урман полосасының көньяк ягы буйлап, алга таба 0,74 км, электр тапшыру линияләрен кисеп үтеп, Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 101 нче урман кварталы кишәрлекләренең төньяк чиге буйлап уза, алга таба чик төньякка таба 1,50 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 31 нче һәм 25 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, алга таба 1,90 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 18 нче һәм 16 нчы урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгы Уньжинский участок урманчылыгындагы 105 нче урман кварталы арасындагы ачыклык буенча Шора елгасына кадәр уза, аның кисеп үтә, алга таба 0,47 км Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы 177 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза.

45 нче ноктадан 46 нчы ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 0,63 км Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы 177 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, аннары 0,76 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 13 нче урман кварталы һәм Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы 177 нче урман кварталы арасындагы ачыклык буйлап уза.

46 нчы ноктадан 47 нче ноктага кадәр чик гомуми төньяк-көнчыгыш юнәлештә 4,20 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 13, 14, 3 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы 173, 174, 175, 171 нче урман кварталлары арасындагы ачыклык буенча Минерка елгасына кадәр уза, аны кисеп үтә, аннары 2,38 км шул ук юнәлештә Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгы 3, 4, 1 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы 171 нче, 163 нче урман кварталлары арасындагы ачыклык буенча уза.

47 нче ноктадан 48 нче ноктага кадәр чик гомуми көнчыгыш юнәлештә 0,88 км, Сурка елгасын кисеп үтеп, 7,19 км Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы 163 нче, 153 нче урман кварталлары һәм Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталы арасындагы чик буйлап уза, алга таба 7,19 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 1, 2, 7, 8, 9, 10 нчы урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы 153, 164, 165, 166, 156, 87, 88 нче урман кварталлары арасындагы ачыклык буенча уза.

48 нче ноктадан 49 нчы ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,95 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 11 нче, 12 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы 88, 89, 90 нчы урман кварталлары арасындагы ачыклык буенча, алга таба 0,36 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгынлагы 12 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары 1,16 км, Шора елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары шул ук юнәлештә 0,31 км, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, урман массивының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, алга таба 1,73 км Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы 101 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза.

49 нчы ноктадан 50 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнбатыш юнәлештә 1,42 км Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза.

50 нче ноктадан 51 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнбатыш юнәлештә 2,45 км ике урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, аннары шул ук юнәлештә 1,13 км Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы урман массивының төньяк-көнбатыш чиге һәм урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы арасыннан, алга таба 0,94 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап уза.

51 нче ноктадан 52 нче ноктага кадәр чик көньяк юнәлештә 0,47 км урман полосасының көнчыгыш ягы буйлап, алга таба 0,52 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә 2,07 км, исемсез инешне һәм урманның аерымланган массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 0,44 км урман полосасының һәм урманның аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап уза, аннары чик 1,19 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 37 нче, 38 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза.

52 нче ноктадан 53 нче ноктага кадәр чик 3,03 км көньяк-көнчыгыш юнәлештә, Кичү елгасын кисеп үтеп, Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 38, 39, 40 нчы урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы урман массивы арасындагы чик буйлап, алга таба 0,76 км урман полосасының көньяк ягы буйлап уза.

53 нче ноктадан 54 нче ноктага кадәр чик гомуми төньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,21 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 0,43 км урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары 2,04 км, исемсез инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

54 нче ноктадан 55 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,68 км, Нуса елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 0,68 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, аннары 0,43 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм урман массивының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, алга таба 0,86 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап уза.

55 нче ноктадан 56 нчы ноктага кадәр чик төньяк-көнбатыш юнәлештә 1,40 км урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, алга таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,30 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, аннары 0,55 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 1,01 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап һәм урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары 1,12 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Шука елгасын кисеп үтеп, яшь урман участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза.

56 нчы ноктадан 57 нче ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә 3,32 км, Сәрдә елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

57 нче ноктадан 58 нче ноктага кадәр чик көньяк юнәлештә 0,64 км урман полосасының көнбатыш ягы буйлап автомобиль юлына кадәр, алга таба 2,63 км Марий Эл Республикасы Мари-Турекский районы Сардаял торак пунктына бара торган автомобиль юлының көнбатыш ягы буйлап, аннары чик, сынык сызык ясап, гомуми юнәлештә көнбатышка таба 3,13 км, Сәрдә елгасын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сәрдәбаш торак пунктына бара торган автомобиль юлын кисеп үтеп, урман полосасының көньяк ягы буйлап уза.

58 нче ноктадан 59 нчы ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,68 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Сәрдәбаш торак пунктына бара торган автомобиль юлын кисеп үтеп, аннары көньякка таба 2,82 км урман полосасының көнчыгыш ягы буйлап уза.

59 нчы ноктадан 60 нчы ноктага кадәр чик көнчыгыш юнәлештә 1,70 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Сәрдә елгасына кадәр уза, аны кисеп үтә, алга таба 5,15 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза.

60 нчы ноктадан 61 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 3,02 км озак вакытка салынган ызан буйлап, алга таба 0,89 км көнчыгышка таба озак вакытка салынган ызан буйлап һәм урман полосасының төньяк ягы буйлап, аннары 1,19 км төньякка таба урман полосасының көнчыгыш ягы буйлап уза.

61 нче ноктадан 62 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,87 км озак вакытка салынган ызан буйлап, алга таба төньяк-көнбатыш юнәлештә 0,78 км урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, аннары төньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,88 км, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза. Алга таба чик көнчыгышка таба 1,81 км, Зур Карлыган – Субаш автомобиль юлын кисеп үтеп, урман полосасының көньяк ягы буйлап уза.

62 нче ноктадан 63 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 2,93 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап уза, аннары 1,20 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Балтач участок урманчылыгындагы 25 нче урман кварталы кишәрлекләренең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, алга таба 2,18 км төньякка таба кибеп баручы инеш буйлап, аннары төньяк-көнчыгышка таба 0,36 км, Арбор елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, алга таба 0,72 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Балтач участок урманчылыгындагы 133 нче урман кварталы кишәрлекләренең көнбатыш һәм төньяк чиге буйлап уза.

63 нче ноктадан 64 нче ноктага кадәр чик төньяк юнәлештә 0,92 км урман полосасының көнбатыш ягы буйлап, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатыш юнәлештә 0,98 км, алга таба 1,37 км төньяк-көнчыгыш юнәлештә уза.

64 нче ноктадан 65 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнбатыш юнәлештә 2,26 км урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап уза.

65 нче ноктадан 66 нчы ноктага кадәр чик гомуми көнбатыш юнәлештә 3,17 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк ягы буйлап, алга таба 4,40 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Балтач участок урманчылыгындагы 9, 8, 7, 6, 5 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, аннары төньяк юнәлештә 1,60 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Балтач участок урманчылыгындагы 5 нче, 1 нче урман кварталлары һәм Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы урман массивы арасындагы ачыклык буенча уза, алга таба чик көнчыгышка таба 1,24 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Балтач участок урманчылыгындагы 1 нче һәм 2 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап Татарстан Республикасы, Марий Эл Республикасы һәм Киров өлкәсе чикләренең тоташу (уртак) ноктасы булган 66 ноктага кадәр уза.

**Татарстан Республикасының «Урман массивындагы Тюшумка елгасы тугаендагы» анклавы**

67 нче ноктадан 68 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә 0,13 км автомобиль юлының көньяк-көнбатыш ягы буйлап уза.

68 нче ноктадан 69 нчы ноктага кадәр чик көньяк юнәлештә 1,48 км Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Семи-Солинский участок урманчылыгындагы 83 нче, 93 нче урман кварталлары чиге буйлап Тюшумка елгасына кадәр уза.

69 нчы ноктадан 67 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнбатыш юнәлештә 1,98 км Тюшумка елгасы уртасыннан агым уңаена аска таба уза.

**Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталы» анклавы**

70 нче ноктадан 71 нче ноктага кадәр чик төньяк-көнчыгыш юнәлештә 2,04 км Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Уньжинский участок урманчылыгындагы 75 нче, 64 нче урман кварталлары һәм Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталы кишәрлекләре арасындагы чик буйлап уза.

71 нче ноктадан 72 нче ноктага кадәр чик көньяк-көнчыгыш юнәлештә 1,38 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталы һәм Марий Эл Республикасы Моркинский урманчылыгының Уньжинский участок урманчылыгындагы 64 нче һәм Марий Эл Республикасы Мари-Турекский урманчылыгының Ямбаторский участок урманчылыгындагы 176 нчы урман кварталлары арасындагы ачыклык буйлап, алга таба 0,57 км көньяк-көнбатыш юнәлештә Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,02 км көньякка таба Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталы кишәрлекләре чикләре буйлап уза.

72 нче ноктадан 70 нче ноктага кадәр чик көнбатыш юнәлештә 1,42 км Татарстан Республикасы Арча урманчылыгының Тукай участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталы кишәрлекләренең көньяк чиге буйлап уза.